МБДОУ «Шубанский детский сад»

Конспект занятия по математике в старшей группе на тему

# «Итоговое занятие по математике»

Подготовила воспитатель I категории
МБДОУ: Закирова Гульнар Исрафиловна

# Математикадан йомгаклау дәресе
(Өлкәннәр төркеме)

ТЕМА: Математик автобуста сәяхәт.

МАКСАТ: Балаларның 10 саны эченлә дөрес санау күнекмәләрен ныгыту.
Геометрик фигураларны исемнәрен атап аеру.
Төсләрне тану.
Фикерләү сәләтен үстерү.
Музыка ярдәмендә дөрес санау.

ҖИҺАЗЛАУ: Стенада кәгазьгә ясалган зур автобус рәсеме; икешәрләп бербер артлы урындыклар - автобус; урындыкларга төрле геометрик фигуралар ябыштырылган; балаларда билетлар - 5 чеби рәсеме, урыны 5 цифралы урындык; бүлмәнең бер почмагында алан - үлән, чәчәк рәсемнәре; уен өчен битлекләр.

МЕТОДИК АЛЫМНАР: Кереш уен, рәсемнәр, күрсәтмә-теоретик материал, техник чаралар куллану.

ӘЗЕРЛЕК ЭШЛӘРЕ: Санарга өйрәнү, геометрик фигураларны тану, төсләрне аеру.
"Кәҗә бәтие санарга өйрәнгән" уенын уйнау.

## ШӨГЫЛЬ БАРЫШЫ

### Оештыру моменты (балалар түгәрәктә)


- Барыгыз да бер-берегезнең кулларыннан тотыгыз. Иптәшегездән килгән җылыны тоясызмы? Кысыбрак тотыгыз.
Кояш җылыта дип хис итегез. Бер-берегезгә карап елмаегыз. Сезнең елмаю - бер-берегезгә кояш елмаюы ул.


### Максатны аңлату

- Бүген без сезнең белән математик автобуска утырып сәяхәткә чыгарбыз. Автобуска утыру өчен билет алырга кирәк. Билетлар гади түгел, аларга геометрик фигура рәсемнәре төшерелгән. Кем шул билет белән үз урынын тизрәк таба, шул безнең белән сәяхәткә бара.

*1 бирем.* Утырып барабыз.

Күңелсез булмасын өчен сөйләшеп барыйк. Рәссам абый безгә





рәсемнәр бүләк итте.

Бу рәсемнәрне рәссам нинли геметрик фигуралар кулланып ясаган?

*2 бирем.* Алан да.

Атнада ничә көн? Атнаның беренче көне (икенче, өченче...)?

*3 бирем.* Вагонда.

Зәки абый урманда утын кисә. әйдәгез, аның балта тавышын саныйбыз. Сезнең билетларыгызның артында рәсемнәр бар, кемнең рәсем саны сорауга туры килә - шул кеше карточкасын күтәрә.

*4 бире*
*м.*
Аланда
.
Мәсьәл
ә чишү.
Монда куяннар кишер
ашыйлар. Барлык куяннарга
да кишер җитәме? Аларның
саны тигез булсын өчен
нәрсә эшләргә кирәк?

*5 бирем.* Вагонда.

Урман җанварлары табышмак язып хат җибәргәннәр, тыңлагыз.

- Без, без,
без идек, Без
биш урманчы
идек. Килде
тагын
беребез,
Ничәү
булдык инде
без?

• Без, без, без идек, Без жиде туган идек. Икебез китте урманга, Ничәү калдык инде без?

Агачта 6 чыпчык, 2се очып китте. Ничә чыпчык калды?

Һавада 2 үрдәк очып бара иде. Аларга тагын 1 үрдәк килеп кушылды. Ничә үрдәк булды?

*6 бирем.* Аланда.

"Кәҗә бәтие санарга өйрәнгән" уенын уйнау.

Кәҗә бәтие -1

Бүре - 2

Ат - 3

Сыер - 4

Аю - 9 Эт - 5 Каз-10

Песи - 6

Төлке - 7

Куян - 8

Кәҗә бәтие кемне ничәнче итеп санаган? Беренче - үзе, икенче - бүре, һ.б.

*7 бирем.* Алан да. х/у "Үз өеңне тап"

а) фигуралар буенча;

б) төсләр буенча.







*8 бирем.* Елга. Анда күпер бар. Кем 10га кадәр саный белә, шул гына елганың теге ягына чыга.

10га кадәр санау - русча, татарча.

# ЙОМГАКЛАУ

Бу дәрес-сәяхәтебез тәмамланып килә. Мин бүген сезнең тапкырлыгыгызны, саннарны, геометрик фигураларны белүегезне тикшердем.